ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

27.10.2021 — 02

пос. Октябрьский

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский  авыл җирлегенең
Яңа Болгар   авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 13 нче ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең   Яңа Болгар   авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең  Яңа Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган  кешедән 2022 нче елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Яңа Болгар авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау
- Зиратны төзеклөндерүавылына керү юлында күпергә таш җәю

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Яңа Болгар авыл клубы бинасында халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Яңа Болгар авылы, Школьная урамы, 42 йорт, 11.00 сәгатьтә.

4 Халык җыенын Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов